**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6460**
**20.07.2023**

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 25 декабрендәге 7326 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 86 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 25 декабрендәге 7326 номерлы карарына (2021 елның 3 декабрендәге 7864 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турында нигезләмәдә:

- 6 пунктта «Башкарма комитетның әлеге нигезләмәне раслаган карары чыккан көннән башлап 3 эш көне эчендә» сүзләрен «агымдагы елның 1 ноябренә кадәр срокта» сүзләренә алмаштырырга;

- 8 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Карар кабул ителгән көнне комиссия, Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турында Башкарма комитет карары проектын әзерләү өчен, беркетмәне Башкарма комитетның финанс идарәсенә җибәрә.»;

- түбәндәге эчтәлектәге 9.1 пункт өстәргә:

«9.1. Башкарма комитетның финанс идарәсе, комиссия беркетмәсе кергән көннән башлап өч эш көне эчендә, Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турында Башкарма комитет карары проектын әзерләүне һәм килештерүне гамәлгә ашыра.»;

- 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турында Башкарма комитет карары һәм Башкарма комитет һәм бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алучы арасында төзелгән шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

2) Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне бүлү буенча комиссия турында нигезләмәдә:

- 7 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 5 пунктча өстәргә:

«5) комиссия беркетмәсе имзаланган көнне аны Башкарма комитетның финанс идарәсенә җибәрә.»;

3) Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне бүлү буенча комиссия составында:

- комиссия составыннан чыгарырга:

Николаев Александр Николаевичны;

Хөсәенова Альбина Шамил кызын;

- комиссия составына кертергә:

Ногманов Рөстәм Марат улын – комиссия әгъзасы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча Сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе (килешү буенча);

Сухова Галина Николаевнаны – комиссия секретаре, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча Сәламәтлек саклау идарәсенең сәламәтлек саклау ресурслары белән оештыру-икътисадый идарә итү бүлеге консультанты (килешү буенча).

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов